БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«06» 03 2025 ел

**КАРАР**

№ 103

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгариф өлкәсе педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати - методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 167 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 15-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 2 августындагы «2022 елның 29 мартындагы «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турындагы» 583/22 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында» 1381/24 номерлы боерыгы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлеше һәм Балтач муниципаль район Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати - методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 167 номерлы мәгариф өлкәсе педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати – техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче бүлектә 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати - методик бүлек хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладмы күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яисә "дипломлы белгеч " квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Олкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |

| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары; | - | - | 20329,0 |
| | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы структур бүлек бүлекчәсе мөдире (башлыгы); | | | 20405,0 |

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.12 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.12. | «Молодость и Профессионализм».»күкрәк билгесе. |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча), «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов